# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, отлову и содержанию безнадзорных животных, защите населения от болезней, общих для человека и животных»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 октября 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 13 января 2012 года № 9-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, отлову и содержанию безнадзорных животных, защите населения от болезней, общих для человека и животных» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I часть) следующие изменения:

1) в наименовании слова «отлову и содержанию безнадзорных животных, защите населения от болезней, общих для человека и животных» заменить словами «защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными»;

2) преамбулу изложить в следующей редакции:

«Настоящий Закон в соответствии с федеральными законами от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления

в Российской Федерации», от 27 декабря 2018 года № 498-ФЗ «Об ответственном обращении с животными и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан наделяет органы местного самоуправления муниципальных районов и городских округов (далее – органы местного самоуправления) отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными.»;

3) в части 1 статьи 1:

а) абзац первый изложить в следующей редакции:

«1. Органы местного самоуправления наделяются следующими государственными полномочиями Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными (далее также – государственные полномочия):»;

б) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) организация мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев;»;

в) пункты 5 и 6 признать утратившими силу;

4) в части 2 статьи 2 слова «Государственными полномочиями, предусмотренными пунктами 4 – 6» заменить словами «Государственным полномочием, предусмотренным пунктом 4»;

5) часть 2 статьи 5 изложить в следующей редакции:

«2. Определение общего объема субвенций, предоставляемых местным бюджетам на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий, производится в соответствии с Методикой определения общего объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления отдельных государственных полномочий Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными, согласно приложению к настоящему Закону.»;

6) приложение изложить в следующей редакции:

«Приложение
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного
самоуправления муниципальных
районов и городских округов
отдельными государственными
полномочиями Республики Татарстан
в сфере организации проведения
мероприятий по предупреждению и
ликвидации болезней животных,
их лечению, защите населения от
болезней, общих для человека и
животных, а также в области
обращения с животными»

**Методика определения общего объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления отдельных государственных полномочий Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными**

1. Настоящая Методика разработана в соответствии с Бюджетным кодексом Российской Федерации, Бюджетным кодексом Республики Татарстан.

2. Методика предназначена для определения общего объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления отдельных государственных полномочий Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными.

3. Общий объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий, определяется по формуле:

$$S = \sum_{i=1}^{m} HP_i,$$

где:

S – общий объем субвенций бюджетам муниципальных образований на осуществление государственных полномочий, в рублях;

$HP_i$ – объем субвенций бюджету i-го муниципального образования на осуществление государственных полномочий, в рублях;

m – число муниципальных образований в Республике Татарстан, бюджетам которых предоставляются субвенции на осуществление государственных полномочий.

4. Объем субвенций бюджету i-го муниципального образования на осуществление государственных полномочий определяется исходя из нормативных расходов на содержание сибиреязвенных скотомогильников и биотермических ям, принятие мер по обеспечению их безопасности и консервацию биотермических ям, а также на организацию мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев по формуле:

$$НР_i = НРсс_i + НРбя_i + НРж_i,$$

где:

$НРсс_i$ – нормативные расходы на содержание, принятие мер по обеспечению безопасности сибиреязвенных скотомогильников в i-м муниципальном образовании, в рублях;

$НРбя_i$ – нормативные расходы на содержание, принятие мер по обеспечению безопасности и консервацию биотермических ям в i-м муниципальном образовании, в рублях;

$НРж_i$ – нормативные расходы на организацию мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев, обитающими на территории i-го муниципального образования, в рублях.

5. В расходы на содержание сибиреязвенных скотомогильников и биотермических ям, принятие мер по обеспечению их безопасности и консервацию биотермических ям включаются:

1) для сибиреязвенного скотомогильника – обслуживание сибиреязвенного скотомогильника, включая текущий ремонт и уборку территории сибиреязвенного скотомогильника;

2) для биотермической ямы:

а) дезинфекция территории и конструкции биотермической ямы;

б) обслуживание, эксплуатация и консервация биотермической ямы, включая текущий ремонт конструкции и уборку территории биотермической ямы.

6. В расходы на организацию мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев включаются:

1) отлов животных без владельцев;

2) транспортировка животных без владельцев в приют для животных и возврат животных без владельцев, не проявляющих немотивированной агрессивности, на прежние места их обитания;

3) лечебно-профилактические мероприятия в отношении животных без владельцев (в том числе вакцинация, дегельминтизация, дезинсекция);

4) содержание животных без владельцев в приюте для животных (в том числе возврат потерявшихся животных их владельцам, а также поиск новых владельцев животным без владельцев, поступившим в приют для животных);

5) стерилизация (кастрация) животных без владельцев;

6) умерщвление животных без владельцев, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного, и утилизация трупов животных без владельцев.

7. Нормативные расходы на дезинфекцию территории и конструкции биотермической ямы определяются исходя из утвержденной уполномоченным в области ветеринарного дела органом исполнительной власти Республики Татарстан рекомендуемой стоимости услуги по дезинфекции 1 кв. метра территории биотермической ямы, оказываемой государственными ветеринарными учреждениями Республики Татарстан гражданам и юридическим лицам.

8. Нормативные расходы на содержание сибиреязвенных скотомогильников и нормативные расходы на обслуживание, эксплуатацию, консервацию биотермических ям определяются исходя из нормативов среднегодовых затрат на ремонт и содержание объектов внешнего благоустройства, утвержденных нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, с применением индекса изменения стоимости строительно-монтажных работ.

9. Нормативные расходы на отлов животных без владельцев, транспортировку животных без владельцев в приют для животных и возврат животных без владельцев, не проявляющих немотивированной агрессивности, на прежние места их обитания, лечебно-профилактические мероприятия в отношении животных без владельцев, содержание животных без владельцев в приюте для животных, стерилизацию (кастрацию) животных без владельцев, умерщвление животных без владельцев, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного, утилизацию трупов животных без владельцев определяются в соответствии с социальными стандартами и натуральными нормами, утвержденными нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан (далее – социальные стандарты и натуральные нормы).

10. Нормативные расходы i-го муниципального образования на содержание сибиреязвенных скотомогильников и биотермических ям, принятие мер по обеспечению их безопасности, консервацию биотермических ям определяются по формулам:

1) для сибиреязвенных скотомогильников:

$$НРсс_i = S_{сс}^i \, x \, НО,$$

где:

$S_{сс}^i$ – общая площадь сибиреязвенных скотомогильников в i-м муниципальном образовании;

$НО$ – нормативные расходы на содержание 1 кв. метра территории сибиреязвенного скотомогильника, в рублях;

2) для биотермических ям:

$$НРбя_i = S_{бя}^i \, x \, (НД + НЭ),$$

где:

$S_{бя}^i$ – общая площадь биотермических ям в i-м муниципальном образовании;

*НД* – нормативные расходы на дезинфекцию территории и конструкции 1 кв. метра биотермической ямы, в рублях;

*НЭ* – нормативные расходы на обслуживание, эксплуатацию и консервацию 1 кв. метра территории биотермической ямы, в рублях.

11. Нормативные расходы i-го муниципального образования на организацию мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев определяются по формуле:

$$HPж_i = HPo_i + HPt_i + HPl_i + HPc_i + HPk_i + HPm_i,$$

где:

$HPo_i$ – нормативные расходы на отлов животных без владельцев для i-го муниципального образования, в рублях;

$HPt_i$ – нормативные расходы на транспортировку животных без владельцев в приют для животных и возврат животных без владельцев, не проявляющих немотивированной агрессивности, на прежние места их обитания для i-го муниципального образования, в рублях;

$HPl_i$ – нормативные расходы на лечебно-профилактические мероприятия в отношении животных без владельцев для i-го муниципального образования, в рублях;

$HPc_i$ – нормативные расходы на содержание животных без владельцев в приюте для животных для i-го муниципального образования, в рублях;

$HPk_i$ – нормативные расходы на стерилизацию (кастрацию) животных без владельцев для i-го муниципального образования, в рублях;

$HPm_i$ – нормативные расходы на умерщвление животных без владельцев, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного, и утилизацию трупов животных без владельцев для i-го муниципального образования, в рублях.

12. Нормативные расходы на отлов животных без владельцев для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPo_i = K_i \, x \, Hpo,$$

где:

$K_i$ – норматив количества животных без владельцев, подлежащих отлову;

$Hpo$ – норматив расходов на отлов одного животного без владельца, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях.

13. Норматив количества животных без владельцев, подлежащих отлову, определяется для каждого муниципального района и городского округа исходя из численности населения, постоянно проживавшего на территории муниципального района или городского округа на 1 января текущего финансового года, по формуле:

$$K_i = \frac{G_i^{mp}}{1000} x \ N,$$

где:

$G_i^{mp}$ – численность жителей i-го муниципального района, городского округа;

$N$ – норматив количества животных без владельцев на 1000 человек, который устанавливается нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан;

1000 – величина, приводящая численность жителей муниципального района, городского округа к показателю, кратному 1000.

14. Нормативные расходы на транспортировку животных без владельцев в приют для животных и возврат животных без владельцев, не проявляющих немотивированной агрессивности, на прежние места их обитания для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPt_i = HPt_i^m + HPt_i^o,$$

где:

$HPt_i^m$ – нормативные расходы на транспортировку животных без владельцев в приют для животных для i-го муниципального образования, в рублях;

$HPt_i^o$ – нормативные расходы на транспортировку животных без владельцев на прежние места их обитания для i-го муниципального образования, в рублях.

15. Нормативные расходы на транспортировку животных без владельцев в приют для животных для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPt_i^m = \frac{K_i}{5} x\, Hpt,$$

где:

$Hpt$ – норматив расходов на транспортировку животных без владельцев, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях;

5 – среднее количество животных без владельцев, транспортируемых за одно мероприятие по отлову животных без владельцев.

16. Нормативные расходы на транспортировку животных без владельцев на прежние места их обитания для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPt_i^o = \frac{[K_i - (K_i\, x\, (K_i^a + K_i^m)]}{5} x\, Hpt,$$

где:

$K_i^a$ – доля животных без владельцев, проявляющих немотивированную агрессивность в отношении других животных или человека и оставленных на содержание в приюте для животных до наступления их естественной смерти, от норматива количества животных без владельцев, подлежащих отлову, для i-го муниципального образования, равная 0,05;

$K_i^m$ – доля животных без владельцев, подлежащих умерщвлению в связи с наличием тяжелого неизлечимого заболевания или неизлечимых последствий острой травмы, несовместимых с жизнью животного, от норматива количества

животных без владельцев, подлежащих отлову, для i-го муниципального образования, равная 0,05;

5 – среднее количество животных без владельцев, транспортируемых за одно мероприятие по возврату животных без владельцев на прежние места их обитания.

17. Нормативные расходы на лечебно-профилактические мероприятия в отношении животных без владельцев для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPl_i = K_i \, x \, Hpl \, ,$$

где $Hpl$ – норматив расходов на лечебно-профилактические мероприятия в отношении одного животного без владельца, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях.

18. Нормативные расходы на содержание животных без владельцев в приюте для животных для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPc_i = (K_i \, x \, 20 + K_i \, x \; K_i^a \, x \, 345) \, x \, Hpc + \; K_i^0 \, x \, Hpc \, x \, 365,$$

где:

20 – количество календарных дней, необходимых для обязательного карантинирования животных без владельцев, поступивших в приют для животных, на выявление у них инфекционных заболеваний (10 календарных дней), а также для послеоперационного содержания животных без владельцев в приюте для животных (10 календарных дней);

$Hpc$ – норматив расходов на содержание одного животного без владельца в приюте для животных в течение одного календарного дня, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях;

$K_i^0$ – количество животных без владельцев, проявляющих немотивированную агрессивность в отношении других животных или человека и оставленных на содержание в приюте для животных до наступления их естественной смерти в отчетном финансовом году, для i-го муниципального образования, определенное на основании представленных органами местного самоуправления в уполномоченный в области ветеринарного дела орган исполнительной власти Республики Татарстан отчетов об осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий в соответствии со статьей 8 настоящего Закона;

345 – количество календарных дней за вычетом периодов карантинирования и послеоперационного содержания животных без владельцев;

365 – количество дней в году.

19. Нормативные расходы на стерилизацию (кастрацию) животных без владельцев для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPk_i = K_i \, x \, K\text{ж} \, x \, Hpk_s + K_i \, x \, K\text{м} \, x \, Hpk_k,$$

где:

$K\text{ж}$ – доля особей женского пола от норматива количества животных без

владельцев, подлежащих отлову, для i-го муниципального образования, равная 0,5;

$Hpk_s$ – норматив расходов на стерилизацию одного животного без владельца, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях;

$Км$ – доля особей мужского пола от норматива количества животных без владельцев, подлежащих отлову, для i-го муниципального образования, равная 0,5;

$Hpk_k$ – норматив расходов на кастрацию одного животного без владельца, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях.

20. Нормативные расходы на умерщвление животных без владельцев, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного, и утилизацию трупов животных без владельцев для i-го муниципального образования определяются по формуле:

$$HPm_i = K_i \, x \, K_i^m \, x \, Hpm,$$

где $Hpm$ – норматив расходов на умерщвление одного животного без владельца и утилизацию трупа одного животного без владельца, определенный социальными стандартами и натуральными нормами, в рублях.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2020 года.

2. При определении объема субвенций бюджету i-го муниципального образования на осуществление государственного полномочия Республики Татарстан по организации мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев на 2021 год количество животных без владельцев, проявляющих немотивированную агрессивность в отношении других животных или человека и оставленных на содержание в приюте для животных до наступления их естественной смерти в отчетном финансовом году, определяется в размере 5 процентов от норматива количества животных без владельцев, подлежащих отлову в i-м муниципальном образовании.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
16 ноября 2019 года
№ 82-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 23 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен төшереп калдырырга, «өлкәсендә» сүзеннән соң «, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

2) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары)

хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирә.»;

3) 1 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының түбәндәге дәүләт вәкаләтләре (алга таба шулай ук – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:»;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру чараларын оештыру;»;

в) 5 һәм 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4) 2 статьяның 2 өлешендә «4 – 6 пунктларында каралган дәүләт вәкаләтләре» сүзләрен «4 пунктында каралган дәүләт вәкаләте» сүзләренә алмаштырырга;

5) 5 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү, әлеге Законга кушымта нигезендә, Хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү методикасына таянып гамәлгә ашырыла.»;

6) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр<br>округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар<br>чирләрен кисәтү һәм бетерү,<br>аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән<br>халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә,<br>шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә<br>Татарстан Республикасының<br>аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>кушымта

**Хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү методикасы**

1. Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде.

2. Методика хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен каралган.

3. Дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = \sum_{i=1}^{m} HP_i,$$

монда:

$S$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләрнең гомуми күләме, сумнарда;

$HP_i$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләме, сумнарда;

$m$ – Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетларына субвенцияләр бирелә торган муниципаль берәмлекләр саны.

4. I-муниципаль берәмлеге бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләме мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә, биотермик чокырларны консервацияләүгә, шулай ук хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыруга норматив чыгымнардан чыгып билгеләнә:

$$HP_i = HPсс_i + HPбя_i + HPж_i,$$

монда:

$HP_{CC_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләрен карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә норматив чыгымнар, сумнарда;

$HP_{БЯ_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә биотермик чокырларны карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә һәм аларны консервацияләүгә норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPж_i$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендә яши торган хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыруга норматив чыгымнар, сумнарда.

5. Мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү чыгымнарына түбәндәгеләр керә:

1) мал-туарның түләмә чире каберлеге өчен – мал-туарның түләмә чире каберлегенә кагылышлы хезмәтләр күрсәтү, моңа мал-туарның түләмә чире каберлегенә агымдагы ремонт үткәрү һәм аның территориясен җыештыру да керә;

2) биотермик чокыр өчен:

а) биотермик чокыр территориясен һәм конструкциясен дезинфекцияләү;

б) биотермик чокырга кагылышлы хезмәтләр күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм консервацияләү, моңа биотермик чокыр конструкциясенә агымдагы ремонт үткәрү һәм аның территориясен җыештыру да керә.

6. Хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру чыгымнарына түбәндәгеләр керә:

1) хуҗасыз йорт хайваннарын аулау;

2) хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютка озату һәм сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз йорт хайваннарын элек яшәгән җирләренә кире кайтару;

3) хуҗасыз йорт хайваннарына карата дәвалау-профилактика чаралары үткәрү (шул исәптән вакцинация, дегельминтизация, дезинсекция);

4) хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютта асрау (шул исәптән югалган йорт хайваннарын хуҗаларына кире кайтару, шулай ук хайваннар өчен булган приютларга эләккән хуҗасыз йорт хайваннарына яңа хуҗалар эзләү);

5) хуҗасыз йорт хайваннарына стерилизация (кастрация) ясау;

6) дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итү һәм хуҗасыз йорт хайваннары үләксәләрен утильләштерү.

7. Биотермик чокыр территориясен һәм конструкциясен дезинфекцияләүгә норматив чыгымнар гражданнарга һәм юридик затларга биотермик чокыр территориясенең 1 кв. метрын дезинфекцияләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтүгә тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы раслаган бәядән чыгып билгеләнә.

8. Мал-туарның түләмә чире каберлекләрен карап тотуга норматив чыгымнар һәм биотермик чокырларга кагылышлы хезмәтләр күрсәтүгә, аларны эксплуатацияләүгә, консервацияләүгә норматив чыгымнар, төзелеш-монтаж эшләре

бәясенең үзгәрү индексын кулланып, тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлауга һәм карап тотуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган уртача еллык чыгым нормативларыннан чыгып билгеләнә.

9. Хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга, хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютка озатуга һәм сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз йорт хайваннарын элек яшәгән җирләренә кире кайтаруга, хуҗасыз йорт хайваннарына карата дәвалау-профилактика чаралары үткәрүгә, хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютта тотуга, хуҗасыз йорт хайваннарына стерилизация (кастрация) ясауга, дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итүгә, хуҗасыз йорт хайваннары үләксәләрен утильләштерүгә норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган социаль стандартлар һәм натураль нормалар (алга таба – социаль стандартлар һәм натураль нормалар) нигезендә билгеләнә.

10. I-муниципаль берәмлегенең мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә, биотермик чокырларны консервацияләүгә норматив чыгымнары түбәндәге формулалар буенча билгеләнә:

1) мал-туарның түләмә чире каберлекләре өчен:

$$HPcc_i = S^i_{cc}\, x\, HO,$$

монда:

$S^i_{cc}$ – i-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләренең гомуми мәйданы;

*НО* – мал-туарның түләмә чире каберлегенең 1 кв. метрын карап тотуга норматив чыгымнар, сумнарда;

2) биотермик чокырлар өчен:

$$HPбя_i = S^i_{бя}\, x\, (HД + HЭ),$$

монда:

$S^i_{бя}$ – i-муниципаль берәмлегендә биотермик чокырларның гомуми мәйданы;

*НД* – биотермик чокыр территориясенең һәм конструкциясенең 1 кв. метрын дезинфекцияләүгә норматив чыгымнар, сумнарда;

*НЭ* – биотермик чокыр территориясенең 1 кв. метрына хезмәтләр күрсәтүгә, аны эксплуатацияләүгә һәм консервацияләүгә норматив чыгымнар, сумнарда.

11. I-муниципаль берәмлегенең хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыруга норматив чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPж_i = HPo_i + HPt_i + HPl_i + HPc_i + HPk_i + HPm_i,$$

монда:

$HPo_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPt_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютка озатуга һәм сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз йорт хайваннарын элек яшәгән җирләренә кире кайтаруга норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPl_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарына карата дәвалау-профилактика чаралары үткәрүгә норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPc_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютта асрауга норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPk_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарына стерилизация (кастрация) ясауга норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPm_i$ – i-муниципаль берәмлеге өчен дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итүгә һәм хуҗасыз йорт хайваннары үләксәләрен утильләштерүгә норматив чыгымнар, сумнарда.

12. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPo_i = K_i \, x \, Hpo,$$

монда:

$K_i$ – ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативы;

$Hpo$ – хуҗасыз бер йорт хайванын аулауга чыгымнарның социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда.

13. Ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары санының нормативы һәрбер муниципаль район һәм шәһәр округы өчен, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына муниципаль район яисә шәһәр округы территориясендә даими яшәгән халык саныннан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_i = \frac{G_i^{mp}}{1000} x \; N,$$

монда:

$G_i^{mp}$ – i-муниципаль районында, шәһәр округында яшәүчеләр саны;

$N$ – 1000 кешегә хуҗасыз йорт хайваннары санының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән билгеләнә торган нормативы;

1000 – муниципаль районда, шәһәр округында яшәүчеләр санын 1000 гә чагыштырылган күрсәткечкә китерә торган зурлык.

14. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютка озатуга һәм сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хайваннарны элек яшәгән җирләренә кире кайтаруга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPt_i = HPt_i^m + HPt_i^o,$$

монда:

$HPt_i^m$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютка озатуга норматив чыгымнар, сумнарда;

$HPt_i^o$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын элек яшәгән җирләренә кире кайтаруга норматив чыгымнар, сумнарда.

15. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютка озатуга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPt_i^m = \frac{K_i}{5} x\, Hpt,$$

монда:

$Hpt$ – хуҗасыз йорт хайваннарын озатуга социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән норматив чыгымнар, сумнарда;

5 – хуҗасыз йорт хайваннарын аулау буенча үткәрелгән бер чара нәтиҗәсендә озатыла торган хуҗасыз йорт хайваннарының уртача саны.

16. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын элек яшәгән җирләренә кире кайтаруга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPt_i^o = \frac{[K_i - (K_i\, x\, (K_i^a + K_i^m)]}{5} x\, Hpt,$$

монда:

$K_i^a$ – i-муниципаль берәмлеге өчен ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативыннан башка хайваннарга яисә кешегә карата сәбәпсез агрессивлык күрсәтә торган һәм табигый рәвештә үлгәнче хайваннар өчен булган приютта тоту өчен калдырылган хуҗасыз йорт хайваннары өлеше, 0,05 кә тигез;

$K_i^m$ – i-муниципаль берәмлеге өчен ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативыннан дәвалап булмаслык авыр чиренә яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләренә бәйле рәвештә юк ителергә тиешле хуҗасыз йорт хайваннары өлеше, 0,05 кә тигез;

5 – хуҗасыз йорт хайваннарын элек яшәгән җирләренә кире кайтару буенча үткәрелгән бер чара вакытында озатыла торган хуҗасыз йорт хайваннарының уртача саны.

17. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарына карата дәвалау-профилактика чараларына норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPl_i = K_i\, x\, Hpl,$$

монда:

$Hpl$ – бер хуҗасыз йорт хайванына карата дәвалау-профилактикалау чаралары үткәрүгә чыгымнарның социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда.

18. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарын хайваннар өчен булган приютта тотуга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPc_i = (K_i\, x\, 20 + K_i\, x\, K_i^a\, x\, 345)\, x\, Hpc + K_i^0\, x\, Hpc\, x\, 365,$$

монда:

20 – хайваннар өчен булган приютка урнаштырылган хуҗасыз йорт хайваннарын аларда йогышлы авырулар булуны ачыклау максатыннан мәҗбүри карантинга ябу өчен (10 календарь көн), шулай ук хайваннар өчен булган приютта хуҗасыз йорт хайваннарын операциядән соң тоту өчен (10 календарь көн) кирәкле календарь көннәр саны;

***Нрс*** – хайваннар өчен булган приютта хуҗасыз бер йорт хайванын бер календарь көн дәвамында тоту чыгымнарының социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда;

$K_i^0$ – i-муниципаль берәмлеге өчен хисап финанс елында башка хайваннарга яисә кешегә карата сәбәпсез агрессивлык күрсәтә торган һәм табигый рәвештә үлгәнче хайваннар өчен булган приютта тоту өчен калдырылган хуҗасыз йорт хайваннарының саны, ул җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Законның 8 статьясы нигезендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органына җирле үзидарә органнары тапшырган хисаплар нигезендә билгеләнә;

**345** – хуҗасыз йорт хайваннарын карантинга ябу һәм операциядән соң тоту чорларын чигереп, календарь көннәр саны;

**365** – елдагы көннәр саны.

19. I-муниципаль берәмлеге өчен хуҗасыз йорт хайваннарына стерилизация (кастрация) ясауга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPk_i = K_i \, x \, Кж \, x \, Hpk_s + K_i \, x \, Км \, x \, Hpk_k,$$

монда:

***Кж*** – i-муниципаль берәмлеге өчен ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативыннан ана хайваннар өлеше, 0,5 кә тигез;

$Hpk_s$ – хуҗасыз бер йорт хайванына стерилизация ясауга чыгымнарның социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда;

***Км*** – i-муниципаль берәмлеге өчен ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативыннан ата хайваннар өлеше, 0,5 кә тигез;

$Hpk_k$ – хуҗасыз бер йорт хайванына кастрация ясауга чыгымнарның социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда.

20. I-муниципаль берәмлеге өчен дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итүгә һәм хуҗасыз йорт хайваннары үләксәләрен утильләштерүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HPm_i = K_i \, x \, K_i^m \, x \, Hpm,$$

монда:

***Нрт*** – хуҗасыз бер йорт хайванын юк итүгә һәм хуҗасыз бер йорт хайваны үләксәсен утильләштерүгә чыгымнарның социаль стандартлар һәм натураль нормалар белән билгеләнгән нормативы, сумнарда.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга і-муниципаль берәмлеге бюджетына 2021 елга субвенцияләр күләмен билгеләгәндә хисап финанс елында башка хайваннарга яисә кешегә карата сәбәпсез агрессивлык күрсәтә торган һәм табигый рәвештә үлгәнче хайваннар өчен булган приютта тоту өчен калдырылган хуҗасыз йорт хайваннарының саны і-муниципаль берәмлегендә ауланырга тиешле хуҗасыз йорт хайваннары саны нормативының 5 проценты күләмендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 ноябрь
№ 82-ТРЗ